КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1070

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинетының кайбер карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турында» 2010 ел, 7 июнь, 433 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 22 октябрь, 842 нче; 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2018 ел, 27 июнь, 521 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 1 нче пункттагы «163» һәм «2787,14» сан-нарын шул ук эзлеклелектә «146» һәм «2 680,69» саннарына алыштырып, үзгәреш кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турында» 2003 ел, 28 гыйнвар, 55 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе структурасын раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 11 март, 186 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 27 июнь, 521 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе структурасына, аны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә бу карарның 2 нче пунктын тормышка ашыруны тәэмин итә торган оештыру карарларын законнар нигезендә кабул итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 23 ноябрь, 1070 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 23 ноябрь, 1070 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе структурасы**

